КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 гыйнвар г.Казань № 23

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвестиция эшчәнлеге субъекты белән Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы арасында инвестицияле проектны гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү тәртибе һәм шартлары хакындагы нигезләмәне һәм инвестицияле проектны гамәлгә ашыру турында шартнамә формасын раслау хакында» 2006 ел, 24 июль, 377 нче карары белән расланган инвестицияле проектны гамәлгә ашыру турындагы шартнамә формасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвестиция эшчәнлеге субъекты белән Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы арасында инвестицияле проектны гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү тәртибе һәм шартлары хакындагы нигезләмәне һәм инвестицияле проектны гамәлгә ашыру турында шартнамә формасын раслау хакында» 2006 ел, 24 июль, 377 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 22 ноябрь, 652 нче; 2008 ел, 25 июнь, 432 нче; 2008 ел, 26 сентябрь, 710 нчы; 2009 ел, 13 май, 312 нче; 2011 ел, 24 август, 702 нче; 2012 ел, 10 март, 203 нче; 2013 ел, 28 март, 212 нче; 2013 ел, 12 апрель, 248 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2013 ел, 5 ноябрь, 842 нче; 2013 ел, 31 декабрь, 1106 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктта:

2.2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.10. Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына оешмалар табышына салымның, физик затлар керемнәренә салымның, оешмалар мөлкәтенә

салымның, транспорт салымының, җир салымының кушма суммалары һәм тиешле пенялар һәм штрафлар суммалары (салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммаларының һәм оешмалар табышына салым һәм оешмалар мөлкәтенә салым өлешендә артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар (пенялар, штрафлар) суммаларының үзгәрешләре йогынтысын исәпкә алмыйча) хисап елына кадәрге өч ел өчен булып (яисә, Инвестиция эшчәнлеге субъекты төзелгән вакытны исәпкә алып, хисап елына кадәрге башка чор өчен, ләкин ике елдан күбрәк түгел), тиешле тармак буенча тулаем Россия Федерациясендә Россия Федерациясе субъектларының берләштерелгән бюджетларына салымнардан кергән акчалар суммасы үзгәрү күрсәткеченә, ул салымнар һәм җыемнар өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган форма буенча тапшырыла торган тиешле ел өчен икътисадый эшчәнлекнең төп төрләре буенча Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре исәпләп бирелү һәм түләнү турындагы хисап белешмәләренә нигезләнеп билгеләнә, һәм ел йомгаклары буенча индексацияләнгән тиешле салымнарның (пеняларның, штрафларның) (салым ташламаларыннан файдалану өлешендә чагыштырма шартларда) Инвестиция эшчәнлеге субъекты тарафыннан чынбарлыкта түләнгән суммаларының уртача арифметик күрсәткеченнән ким булмаган күләмдә ел саен түләнү.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.2.11 һәм 2.2.12 пунктчалар өстәргә:

«2.2.11. Бу Шартнамәне төзегән көннән 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы адресына исәпләнгән һәм Инвестиция эшчәнлеге субъекты тарафыннан түләнгән салымнар суммалары, салымнар буенча недоимкалар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар һәм артык түләнгән яки артык түләтелгән салымнар (пенялар, штрафлар) суммалары, хисап елыннан алдагы дүртенче елның 1 гыйнварыннан башлап йә Инвестиция эшчәнлеге субъекты төзелгән көннән башлап (әгәр дә Инвестиция эшчәнлеге субъекты соңрак төзелгән булса), ташламалар яктылыгында алынган салым ташламалары суммалары турындагы мәгълүматларны салым органы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бирү өчен ризалык җибәрү.

2.2.12. Ел саен, 15 декабрьгә кадәр, «Икътисадый эшчәнлекнең төп төрләре буенча Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен исәпләү һәм алар керү турында хисап» статистика салым хисабы формасына таянып, Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы нигезендә Инвестиция эшчәнлеге субъектының төп икътисадый эшчәнлеге төреннән чыгып, тиешле елга Федераль салым хезмәтенең статистика салым хисаплылыгы формаларын раслау турында Федераль салым хезмәте боерыгы нигезендә икътисадый эшчәнлекнең кодын сайлауны һәм төп төре исемен нигезләп, хисап елында һәм хисап чорына кадәрге өч ел эчендә Инвестиция эшчәнлеге субъекты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган төп икътисадый эшчәнлек төренең коды һәм исеме турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрү.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә Инвестиция эшчәнлеге субъектына түбәндәге салым ташламалары бирелә:

| Салым төренең исеме | Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган өлештә салым ставкасы, процент | Салым ташламалары суммасы, мең сум | Ташламалар бирү сроклары |
|---|---|---|---|
| Оешмалар мөлкәтенә салым | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |
| Оешмалар табышына салым | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |
| Барысы | | | |

Салым ташламаларының күрсәтелгән суммалары якынча ташламалар булып тора.

Салым ташламаларын бирү әлеге Шартнамәнең 2.2 пунктындагы 2.2.10 пункты нигезендә салымнар һәм җыемнар түләү йөкләмәләрен үтәү шарты белән Инвестиция эшчәнлеге субъектының бухгалтерлык һәм салым хисаплылыгында чагылыш тапкан аның факттагы эшчәнлеге күрсәткечләреннән чыгып, әлеге оешмалар мөлкәтенә салым буенча һәм (яки) оешмалар табышына салым буенча салым ставкалары нигезендә салым чоры йомгаклары буенча гамәлгә ашырыла.

Яңа төзелгән инвестиция эшчәнлеге субъекты тиешле салым буенча беренче салым чоры йомгаклары нигезендә, әлеге Шартнамәнең 2.2 пунктындагы 2.2.10 пунктчасында билгеләнгән шартларны үтәмичә, әлеге оешмалар мөлкәтенә салым буенча һәм (яки) оешмалар табышына салым буенча салым ставкаларын кулланырга хокуклы.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, хисап елыннан соң килә торган елның 15 мартыннан да соңга калмыйча, әлеге Шартнамәнең 2.2 пунктындагы 2.2.10 пунктчасы нигезендә Инвестиция эшчәнлеге субъекты тарафыннан йөкләмәне үтәү (үтәмәү) турында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына хәбәр итә. Әлеге йөкләмәнең үтәлешен бәяләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым һәм оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын куллану шартларын салым түләүчеләрнең аерым категорияләрен үтәүне бәяләү тәртибен һәм методикасын раслау турында» 2020 ел, 15 июнь, 495 нче карары белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым һәм оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын куллану шартларын салым түләүчеләрнең аерым категорияләрен үтәүне бәяләү тәртибе һәм методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы ел саен, 20 мартка кадәр, әлеге Шартнаменең 2.2 пунктындагы 2.2.10 нчы пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салымнар һәм җыемнар түләү йөкләмәләрен үтәве (үтәмәве) турында Инвестиция эшчәнлеге субъектына хәбәрнамә җибәрә.»;

әлеге шартнамә формасына теркәлгән 3 нче кушымтаның 8 пунктындагы таблицада:

түбәндәге юлны:

| | | |
|---|---|---|
| «3. Салым ташламалары күләме, мең сум:<br>табышка салым буенча<br>мөлкәткә салым буенча» | | |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «3. Салым ташламалары күләме, мең сум:<br>оешмалар табышына салым буенча<br>оешмалар мөлкәтенә салым буенча»; | | |

түбәндәге юлны:

| | | |
|---|---|---|
| «7. Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына керүләр – барысы, мең сум,<br>шул исәптән:<br>табышка салым буенча<br>мөлкәткә салым буенча<br>физик затлар керемнәренә салым буенча» | | |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «7. Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына керүләр – барысы, мең сум,<br>шул исәптән:<br>оешмалар табышына салым буенча<br>оешмалар мөлкәтенә салым буенча<br>физик затлар керемнәренә салым буенча»; | | |

әлеге шартнамә формасына теркәлгән 4 нче кушымтада:

2 бүлекнең 2.3 бүлекчәсендә:

түбәндәге юлларны:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән:<br>8.1. Финанс нәтиҗәсенә карый торган салымнар – барысы,<br>шул исәптән:<br>8.1.1. Мөлкәткә салым**<br>8.1.2. Табышка салым**» | | | | | | | | |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән:<br>8.1. Финанс нәтиҗәсенә карый торган салымнар – барысы,<br>шул исәптән:<br>8.1.1. Оешмалар мөлкәтенә салым**<br>8.1.2. Оешмалар табышына салым**»; | | | | | | | | |

2 бүлекнең 2.4 бүлекчәсендә:
түбәндәге юлларны:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән:<br>1.1. Табышка салым буенча<br>1.2. Мөлкәткә салым буенча<br>2. Салым керүләре – барысы,<br>шул исәптән:<br>2.1. Россия Федерациясе бюджетына<br>2.2. Татарстан Республикасы бюджетына – барысы,<br>шул исәптән:<br>2.2.1. Табышка салым<br>2.2.2. Мөлкәткә салым» | | | | | | | | | |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән:<br>1.1. Оешмалар табышына салым буенча<br>1.2. Оешмалар мөлкәтенә салым буенча<br>2. Салым керүләре – барысы,<br>шул исәптән:<br>2.1. Россия Федерациясе бюджетына<br>2.2. Татарстан Республикасы бюджетына – барысы,<br>шул исәптән:<br>2.2.1. Оешмалар табышына салым<br>2.2.2. Оешмалар мөлкәтенә салым». | | | | | | | | | |

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин